СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 8 июленнән бирле чыга. | №67 (7240) | 11 июнь, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Грамота тапшырылды

Татарстан ССРның агропромышленность комплексы Советы президиумы һәм АПК работниклары профсоюзы республика комитеты югары производство күрсәткечләре һәм хезмәт күрсәтү культурасы өчен Октябрь районының «Рассвет» совхозы коллективын Мактау грамотасы белән бүләкли.

## „Большевик" колхозыннан
## Нәтиҗәләре күркәм

«Большевик» колхозының ферма хезмәтчәннәре сөтчелек фронтында җәелдерелгән ярышта күркәм нәтиҗәләргә ирешәләр.

Сыер савучылар арасында Валентина Васильевна Парукова алда бара. Хезмәттәше Вера Петровна Ухвановaның күрсәткече дә аның белән тигезләшә. Бүгенге көндә алар һәр сыердан уртача 16,6 килограмм сөт савалар. Елена Артемьевна Григорьева да әлеге савымчылардан калышмый.

Җәйләүгә чыккач маллар сөтне бермә-бер арттырдылар. Ферма буенча көнлек савым уртача 15,8 килограмм.

## Эшкә керештеләр

Хуҗалыкта АВМ-0,65 агрегаты витаминлы үлән оны әзерли башлады. Оператор Вениамин Родионович Ярунгин үз вазифасына җаваплы карый. Ул эштә тоткарлыклар тудырмаска тырыша. Аңарга улы Геннадий һәм ярдәмче эшчеләр Петр Иванович Яковлев, Александр Григорьевич Еремеев, Анатолий Евгеньевич Краснов булышалар. Яшел массаны кырдан МТЗ-80 тракторы белән Владимир Кимович Алипов китереп тора. Күпьеллык үләнне бер үк вакытта үзе чаба да.

АВМ-0,65 агрегаты көнгә 2 тонна урынына 3 тонна үлән оны әзерли.

## Чөгендердә

Колхоз басуында чөгендер 295 гектар мәйдан били. Бүгенге көндә анда сирәкләү эшләре бара. Колхозчы хатын-кызларга ярдәмгә районның шикәр заводы, саклык банкы, таралар ремонтлау предприятиесе эшчеләре дә килделәр.

Соңгы вакытта тоташ яңгырлар яву сәбәпле татлы тамыр плантацияләренә әле шаровка үткәрелмәде.

Г. ЕРЕМЕЕВ.

«Комбайн» колхозы. Терлекләргә печән оны әзерләүдә ирле-хатынлы Сафиннар беренче көннән үк уртак тырышлык куялар. Алар икесе дә АВМ-0,65 агрегатында унҗиденче елларын, эшлиләр һәм үз эшләрен һәрчак зур җаваплылык хисе белән башкаралар. Мәрьям эшчеләргә наряд яза, ә Мәгъсүм оператор хезмәтен башкара. Мәгъсүмнең шундый төгәл булуы сәбәпледер инде, эштә ватылып тору дигән

## Оешканлык белән

нәрсәне биредәгеләр белмиләр.

АВМга быел унынчы классны тәмамлаган егетләр Гаяз Зарипов, Рөстәм Фәссахов, Айрат Мифтахов та үз теләкләре белән эшкә килделәр. Әнә шулай оешкан төстә, бердәм эшләгәндә борчылырга урын юк.

С. ФӘТХЕТДИНОВА.

## Мөмкинлекләрдән файдаланып

«Знамя Октября» колхозы. Хуҗалыкның беренче товарлыклы-сөтчелек фермасы хезмәтчәннәре агымдагы елда да үз максатларына ирешү һәм эштә темпны тагын да арттыру өчен зур тырышлык куялар. Мария Семеновна Ишмуллина кулдашы Надежда Кузьминична Кадушкина белән бу дүрт айда профилактика группасындагы бозаулардан 594әр грамм уртача тәүлеклек үсеш алуга иреште. Намуслы һәм тырыш хезмәте өчен Мария Семеновнаның рәсеме узган елны районның Мактау тактасына да куелды.

Сыер савучылар арасында исә лидерлык Мөслимә Фатыйховна Галимова кулында. Ул бүгенге көндә һәр сыердан уртача 13,6 килограмм сөт сава. Савымчылар Ирина Мироновна Минзелеева һәм Надежда Евгеньевна Кадушкина исә аңардан азга гына калышалар.

Савымчылар сөт алуда ирешелгәннәр белән генә канәгатьләнмичә, булган бөтен мөмкинлекләрдән дә нәтиҗәле файдаланырга тырышалар. Бу көннәрдә терлекләр өчен яшел конвейер дә хәрәкәткә керде.

Г. КУЛЬМЕТЬЕВА,
экономист.



Мастер итеп билгеләделәр икән инде, димәк син үз участогыңдагы һәрбер кимчелекне, уңышны күрепбелеп торырга, коллективны аңлый белергә тиешсең. Дөрес, скважиналарга җир асты капиталь ремонт үткәрү цехында Разыймның әле мастер булып эшләвенә күп вакыт үтмәде. Һәм хәзергә аның нинди карашлы җитәкче булуын алдан юрау да мөмкин булмас иде. Әмма шулай да ул элек оператор булып эшләү дәверендә үзен алтын куллы, сабыр холыклы кеше итеп танытты инде. Шунлыктан Разыймның биредә дә сынатмасына ышаныч зур.

Рәсемдә: Р. Сәләховны күрәсез.

Сез сораган идегез...

## Борчылырга урын юк

Соңгы көннәрдә район санитария-эпидемиология станциясендә телефон шалтырады: «Сез нишләп тикшермисез? «Огонек» кибетендә Чернобыльдән килгән радиацияле шикәр комы аталар бит!»—диде дулкынланган тавыш.

Шундый звоноклар тагы берничә кабатланды һәм санитария-эпидемиология станциясе, «Норлатнефть» НГДУсы ОРСы вәкилләре катнашында комиссия төзеп, кибеткә юл тотты. Станциянең санитария врачы Ә. Мәхмүтов безгә түбәндәгеләрне хәбәр итә.

—Комиссия Украина ССРның Черновцы шәһәре шикәр заводыннан килгән әлеге шикәр комына дозиметрик анализ үткәрде. Нәтиҗәләрдән күренгәнчә, шикәр комындагы радиация безнең җирлектәге табигый фоннан артмый. 7 июнь көнне ул шәһәрдә сәгатенә 5—7 микрорентген тәшкил иткән иде. Күрәсез, хөрмәтле са п алучылар, борчылырга урын юк.

## ЧӨГЕНДЕР БАСУЫНДА

«Восход» колхозы. Быел чөгендер игүчеләр эшкә шактый соңарып керештеләр, чөнки байтак мәйданда яңадан чәчү үткәрергә туры килде. Хуҗалыкта татлы тамыр 180 гектарда игелә. Аны эшкәртүгә быел да колхоз эшчәннәреннән тыш авыл интеллигенциясе, хезмәткәрләр дә чыкты. Хәзер плантацияләрдә эш кайный. Механикалаштырылган звено җитәкчеләре Аркадий Филиппович Иванов һәм Николай Нагорный рәт араларын эшкәртү үткәрделәр. Аркадий Филиппович бу эштә күптәнге оста инде. 20 елдан бирле шул хезмәттә. Ул эшне җиренә җиткереп башкарырга гадәтләнгән, яшь кулдашы Николайга да чөгендер игү серләрен өйрәтеп калдырырга тырыша. Алар артыннан ук участокларга хатын-кызлар да төштеләр.

Л. ТАРАСОВА,
баш бухгалтер.

## Җирләр сый ала

XXI партсъезд исемендәге колхоз. Хуҗалыкның пар җирләренә органик ашлама чыгару дәвам итә. Аны төяп һәм ташып торуда «Октябрьскремтехпредприятие»дән килгән машиналар ярдәм күрсәтәләр. Хуҗалыктан исә биредә Т-150 маркалы тракторда Рөстәм Ситдиков, Валерий Шәйдуллин, К-701 белән Замир Хәммәтвәлиев әйбәт эшлиләр. Алар тырышлыгы белән соңгы айларда кырларга 4500 тонна өстәмә сый күчерелде инде.

### БИШ АЙ ЙОМГАКЛАРЫ

Колхоз терлекчеләре быелның 5 аен әйбәт кенә күрсәткечләр белән төгәлләделәр. Хуҗалык савучылары арасындагы ярышта 1 урынны өченче бригададан Камилә Шәфигуллина алып тора. Бу чорда ул үз карамагындагы һәр малдан 1423 килограмм сөт сава. Аның хезмәттәше Зәйтүнә Хамматовада исә бу күрсәткеч 1300 килограмм тәшкил итә. Бу бригада хуҗалык сөтчеләре арасында барган ярышта да әйдәп бара. Биредә уртача савым 1196 килограмм.

Ә шәхси беренчелектә өченче урын 2 нче бригада савучысы Нажия Шәйдуллина кулында: ул 1296 килограмм сөт сауды. Терлекчеләр җәйләү чорында сөт муллыгы өчен көрәш темпын киметмиләр. Хәзер хуҗалыкта көнлек савым 11.6 килограмм тәшкил итә. Зәйтүнә Хамматова, Флера Вәлиева кебек уңганнар группасында ул 14,3—13 килограммнан да төшми.

Мал симертүчеләргә килсәк, биредә беренче бригада терлекчесе Шамил Йосыповка тиңнәр юк. Ул үзе карый торган 1 яшькәчә бозауларның 840ар грамм тәүлеклек үсеш бирүен тәэмин итә. Шулай ук бригададан Наил Вәлиев группасында ул 712 грамм.

Ш. ГАТИН,
XXI партсъезд исемендәге колхоз.

## Тигәнәштә сабан туе

Киекле авылына шаулап сабан туе килде. Ул ел саен урманның халык ярата торган Тигәнәш аланында үткәрелә. Тирә-яктагы хозурлык, саф урман исе, күзгә ял бирә торган яшеллек... Әйтерсең лә, табигать бу бәйрәмгә урынын үзе үк әзерләгән. Иртә таңнан алан шау-гөр килде. Киекле, Үрнәк авыл халкы, кайткан кунаклар бихисап иде.

Элеккеге матур гадәт буенча сабан туен ачып җибәрү Киекле мулласы Вәлимөхәммәт ага Хәмәтвәлиевка тапшырылды. Ул тынычлык, бәхет, сафлык, күңелле ял теләде. Аңардан соң сүзне Ульянов исемендәге колхоз рәисе В. М. Даутов алды. Рәис чәчү йомгаклары, колхозчыларның уңышлары, алда торган бурычлар турында сөйләде. Алдынгылар белән таныштырды.

Сабан туйларында үткәрелә торган бөтен уеннар да безнең бәйрәмне дә читләтеп үтмәделәр. Халык барысына да бик теләп катнашты. Иң элек атлар чабышын күзәттеләр. Бу ярышта С.Әхмәтовка тиңнәр булмады. Көрәштә сабан туе батыры булып Фаикъ Хаҗиморатов калды. Ул узган ел район сабан туенда да икенче урынны алган иде. Солтан Хаҗиморатов икенче, Фәрит Сәләхетдинов өченче урында булдылар.

Сәхнәдә Киекленең атаклы җырчылары Клара Гафиятуллина, Салих Фәссахов, Казанда үткәрелгән «Яшь авазлар» конкурсы лауреаты тугыз яшьлек Дилүс Нургатин һәм башка моңлы җырчыларыбыз халыкның яраткан җырларын башкардылар.

Сабан туе күңелле үтте.

Н. ГАТАУЛЛИН.

## Район газетасына 60 яшь

### Дошман һичшиксез тар-мар ителер

Иске Зирекле авылы колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына бездән—кызылармеецлардан ялкынлы сәлам.

Сез, тылда социалистик колхоз кырларыннан мул иген уңышын урып-җыюда тырышып эшләгән вакытта, без монда—фронтта сезнең тыныч хезмәтегезне бозарга, сезнең иркегезне буарга маташучы канәчкеч Гитлер фашизмына каршы каты көрәш алып барабыз.

Дошман мәкерле һәм хәйләкәр. Ләкин аның һәр төрле хәйләкәрлекләренә без каты һәм ныклы отпор бирәбез. Безнең тарафтан җибәрелгән һәрбер пуля, һәрбер граната, һәрбер бомба дошманга үлем китерә. Мин үземнең бөтен көчемне, әгәр кирәк булса тормышымны да җәлләмичә фашистларны җир йөзеннән юк иткәнчегә кадәр көрәшәчәкмен. Без дошманны һичшиксез җиңәрбез, чөнки безнең белән бергә мораль һәм политик яктан корычтай нык булган тыл—сөекле Ватаныбызның ирекле халкы үз-үзен аямыйча дошманга каршы көрәшә.

Сөекле авылдашларым!

Сез дә үзегезнең киң кырларыгыздан сталинчыл мул игенне вакытында, бернинди югалтуларсыз җыеп алу өчен, дәүләткә ашлык тапшыруны срогыннан элек үтәү өчен көрәшегез. Бу фронтка сезнең иң яхшы ярдәмегез булачак.

Сәлам белән авылдашыгыз Гиниятуллин Исмәгыйль. Хәрәкәттәге Кызыл Армия. «Октябрь колхозчысы». 17 август. 1941 ел.

### Илебезнең оборона фондына

«Трактор» колхозы членнары Әтнә районы колхозчыларының мөрәҗәгатен өйрәнгәннән соң үзләренең җыелышларында сугыш беткәнчегә кадәр һәр ай саен 2 шәр хезмәт көнен дәүләт оборона фондына бирү турында карар кабул иттеләр. Колхозчы Вәлиәхмәт Сафин 5 хезмәт көне, 65 яшьлек Шәйдулла Вәлиуллин үзенең кызы Гамбәр белән 4 әр хезмәт көне, Кәрим Зарипов, Бәннат Хәйруллина, Мәҗит Яруллин, Зиннәтулла Вәлиуллиннар 4 әр хезмәт көне бирәчәкләрен белдерделәр.

Г. МОРТАЗИНА.
«Октябрь колхозчысы». 11 сентябрь.

БӘХӘС КЛУБЫ

# Битараф булмыйк

РСФСРга Президент сайлау мәсьәләсе буенча төрле фикерләр туа. Берәүләр Татарстан территориясендә РСФСР Президентын сайлауга каршы чыгалар, икенчеләре, сайлаулар Татарстанга суверенитет бирүгә комачаулый дип уйлыйлар, өченчеләре, мәсәлән, Х. Әхмәтов кебекләр, Рәсәй Президенты итеп тик Б. Н. Ельцинны гына сайларга тәкъдим итәләр. Мондый очраклардан соң укучыга хата кайда, амбиция кайда, алдашу кайда икәнлеген белүе читен. Билгеле, сайлаучылар арасында боларны аера белмәүчеләр дә юк түгел.

Шуңа да мин барлык президентлар, шул исәптән РСФСР президентын сайлауда да үз мөнәсәбәтемне белдерергә булдым. Минем карашка президент идарәсе уңайлы, идарәнең демократик формасы булса да, халык депутатлары Советлары белән сыеша да алмый. Барысы да президент булырга ашкынганга мин үзем РСФСРга Президент итеп Николай Иванович Рыжковны сайларга кирәк дип исәплим.

Ни өчен безгә РСФСР Президентын сайларга кирәк? Беренчедән, россиялеләргә компетентлы президент сайлауда булышу булса, икенчедән, РСФСР территориясендә безнең туганнарыбыз яши. Шуны да онытырга ярамый. Татарстан РСФСР эченә урнашкан. Димәк, аның президенты кем булу безнең өчен барыбер түгел. Халык телендә яхшы өй түгел, яхшы күрше сатып ал, диләр. Безгә дә үзебезгә мөстәкыйльлек белән бергә күршеләребезгә яхшы җитәкче, президент сайлауда булышырга кирәк. Тик шул чакта гына Татарстанның ышанычлы суверенитетына өмет итәргә була.

РСФСР—зур республика. Анда СССРга кергән республикалар халкының яртысы яши һәм ул, Татарстан да аның субъекты булган ныклы Союз нигезе булырга тиеш. РСФСР һәм Союзның Югары власте арасындагы бүлешүләр СССРга кергән барлык республикаларга һәм шул исәптән Татарстанга да зур материаль һәм мораль зыян китерә. Ә Б. Ельцинның үзәк белән тиешле консолидациясе юк һәм була да алмый.

Мин ни өчен Ельцинга каршы тавыш бирергә булдым? Чөнки ул власть ярата, амбициоз кеше, авантюрист һәм президентлык властен үз кулына алып РСФСРга гына түгел, бөтен Союзга төзәтеп бетмәслек зыян китерәчәк. Бу турыда безгә аның якын булышчылары С. П. С.П.Горячева һәм башкалар кисәтү ясадылар.

Б. Ельцин зур дәрәҗәне үз тормышының максаты итеп куя. Бер пресс-конференциядә корреспондентлардан берәү аңа «Сез РСФСР Президенты итеп сайланмасагыз, РСФСР Югары Советы рәисе булып каласызмы?»—дигән сорау бирде. Ул: «Юк»,—диде.

Ә иптәш Х. Х. Әхмәтов үзенең «Тынычлык һәм уртаклык хакына» (1991 елның 30 май санында) дигән мәкаләсендә Б. Ельцинны халык интересларын яклаучы, азатлык өчен көрәшүче, матди кыенлыкларны да халык белән бергә тартучы итеп күрсәтергә тырыша. Имештер, Ельцин «500 көн» программасын эшләгән һәм тормышка ашыра. Иптәш Әхмәтов Ельцинның ул программадан күптән баш тартканын һәм аны И. Силаевның кризиска каршы программасы белән алмаштырганын белми, күрәмсең. Алар ул программадан нигездә авантюрик булган өчен баш тарталар, ә аны иҗат итүче Шаталин Россия кризистан 500 көндә түгел, 40 елдан соң гына чыга алачак, дип исәпли. Бу бит сайлаучыларны алдау.

Ельцин кебек авантюристлар теләсә нәрсә бәрабәренә властькә килергә омтылалар. Тик алар Россиягә яхшылык алып килмәячәкләр, ә халыкны гражданнар сугышына китерәчәкләр. РСФСР Президенты акыллы, уйлап эш итүчән, сакчыл булырга тиеш. Н. И. Рыжков кына шундый Президент була алачак. Ә иптәш Әхмәтов Рыжковны илне катастрофага алып китүдә гаепләргә маташа. Иптәш Рыжков илдә алкоголизмга каршы закон кертүгә, ихтыяҗ зур булган товарларга бәяне күтәрүгә каршы булган бердәнбер кеше иде Политбюрода. Ул акча алмашуга да каршы килде. Бүген дә бәяләр күтәрелүгә каршы.

Иптәш Рыжковның сайлау алды программасы РСФСРны экономик һәм социаль үстерүдә реаль юлда тора. Ул экономикабызны социалистик үстерү позициясендә. Ә Ельцин капиталистик юл белән үстерү позициясен алга сөрә. Әлеге юл РСФСРның күпчелек халкын бөлгенлеккә төшерү юлы.

Мин сайлаулар көнне—12 июньдә Н. И. Рыжковка тавыш бирәчәкмен һәм бу шул ук вакытта Татарстан ССР суверенитетын да саклап калырга булышлык булыр.

**П. НИКУЛИН,**
1942 елдан КПСС члены, сугыш һәм хезмәт ветераны.

# Ялгыш адым ясамыйк

Соңгы көннәрдәге хәлләр һәр аңлы кешене уйланырга, вакыйгаларны анализларга, күпмедер дәрәҗәдә аларның алга таба үсешен фараз кылырга мәҗбүр итә.

Заманның катлаулы чорын кичерәбез. Материаль яктан кыенлыклар күз алдында сыман: талоннар, дефицит, кыйммәтчелек. Аннан чыгу юлы, минемчә, бер генә:бөтен ил, республика белән, һәр район, предприятие, хуҗалыкның, һәр кешенең намуслы хезмәтендә ул. Һәркем закон һәм вөҗданы кушканны намус белән үтәгәндә генә якты киләчәккә өмет тотарга мөмкин. Биредә милекнең төрле формаларын тормышка ашыру, җитәкче постларга инициативалы, экономик яктан грамоталы, иҗади уйларга сәләтле җитәкчеләрне кую да бик мөһим. Ә рухи дөньябыздагы кыенлык—бусы җитди проблема. Биредә фикерләр һәм бәяләр төрле, халыкның аңында буталчыклык. Әмма иң куркынычы—бу билгесезлек, киләчәк тормышны алдан күрү мөмкин булмау. Күпмедер дәрәҗәдә бу халык кәефендә апатия дә сизелә. Якты киләчәкне төзибез, төзибез, ә нәтиҗәдә шул ук ярлылык, шул ук коррупция, блат, шул ук протекция. Халык нинди хокуксыз, чарасыз иде—шундый ук чарасыз булып калды да. Шуннан сорау туа: бу өлкәдә Татарстан суверенитеты нәрсә бирер? Җавап: бернәрсә дә бирмәячәк. Элек министрлык Мәскәүдә иде, хәзер Казанда булачак. Элек Казанда җитәкчелектә йөз кеше иде, хәзер—мең булачак. Элек Казандагы түрә «Волга»да йөри иде, хәзер чит ил машинасын куар. Шундый хәл булмас дип кем әйтә ала? Татар милләте үсәчәк, дибез. Биредә дә арттырып җибәрергә күп кирәкми. Берәү дә әле Норлаттагы мәчеткә яки дәүләт икетеллелегенә каршы килми.Әмма икенче яктан кеше үзе аңлый: баласы югары уку йортына кереп белем алсын өчен, иң элек рус телен әйбәт белергә кирәк. Шунсыз ул Мәскәү Дәүләт университетына яки башка уку йортына керә алмый. Бу—булачак талантлы яшь белгечне югалту үзе үк Татарстан өчен зур югалту. Икенче яктан, татарларга татар телен белү дә зарур. Шунлыктан мәктәпләрдә 2 телдә укыту кертергә, һәр милләтнең үз телен әйбәт үзләштерүенә ирешергә кирәк.

Дәүләт суверенитеты экономик яктан отышлы, диләр. Элек, автономияле республика булганда Татарстанга бик аз күләмдә өлеш чыга иде. Бу безгә ошамый. Республика Үзәккә килешү нигезендә минималь средстволар бирергә тиеш. Инде янә бер сорау—безгә Россия кирәкме? Миңа калса, элеккеге башка автономияле республикалар тикмәгә генә Россия субъекты булып калмаганнар. Автономияле республика никадәр генә бай булса да аңа нык үскән илләр дәрәҗәсенә күтәрелү кыен. Башкортстан бездән ярлырак түгел бит, димәк, ул шуны аңлаган. Мондый авыр вакытта бүлгәләнү түгел, берләшү хәерлерәк. Үткәннәрне дә истән чыгармаска кирәк: шул КамАЗны, Чернобыль АЭСын төзегән төсле үк, бөтен ил корды бит. Власть өчен тарткалашу гына суверенитетка китермәде микән?

Шәхсән мин үзем суверенитетка каршы түгел. Әйдә, Союз һәм Россия белән килешү булсын. Әмма бу милләтчелеккә юл ачарга тиеш түгел. Бездә дә Кыргызстандагы кебек закон нигезендә җирне төп милләт халыкларына гына беркетү булмасмы? Бездә дә качаклар килеп чыкмасмы? Президент сайлау турында сүз алып барганда, шуларны һичшиксез истә тотарга кирәк. Юкса бик ачык әйтелде: Рәсәй президентын сайлау Татарстанга йогынты ясамый, диелде. Шулай булганда, ни өчен күршеләребезгә яхшы президент сайлауда булышмаска? Чөнки безнең үзара мөнәсәбәтләребезгә нык йогынты ясаячак ул. Инде президентлыкка кандидат мәсьәләсенә килгәндә—бусы һәркемнең үз эше. Миңа барлык претендентларның программасы да ошады. Әмма шәхес буларак... Бакатин, Тулеев һәм Рыжков—Россия халкы турында уйланучы, ышаныч уятучы претендентлар шулар. Инде Ельцинга килгәндә, аны алай дип әйтә алмыйм. Аның халык ышанычын какшаткан адымнары шактый булды. Ни өчен иң арзан юл белән дәрәҗә казанырга тырыша икән ул? Бит ул автономияле республикаларга суверенлык вәгъдә итүен дә нәкъ шул максаттан эшләдем дип әйтүдән чирканмады. Димәк, киләчәктә ул үз линиясен үткәрепме үткәрәчәк.

Һәм соңгысы. Сайлаулаулар көне килеп җитте. Һәркем үз позициясен сайларга, республикалар язмышында үз сүзен әйтергә тиеш. Уйлап, үкенмәслек итеп әйтсен иде ул аны.

**В. СЕРГЕЕВ.**
Норлат шәһәре.

### Бөек Ватан сугышы башлануга 50 ел тулуга карата

## Язучы музее



**1941 елның декабре. Ясная Поляна. Бөек рус язучысы Л. Н. Толстойның музей-усадьбасы. Сугыш вакытында музей - усадьба җимерелүгә дучар булган.**

**Сугышның башлануын көтмәгән илебез халкы ул вакытта бик күп әфәтләргә дучар булды. Сугыш үткән җирдә җимереклелекләр, кешеләрне җәзалаулар, ерткычлыкларның чиге булмады.**

**ТАСС фотохроникасы.**

## Совет Президенты катнашырмы?

БЕРЛИН. ГФР тышкы эшләр министры Г. Д. Геншер: шушы елның июлендә Лондонда Көнбатышның җиде төп дәүләте җитәкчеләре очрашуында М. С. Горбачев та катнашыр, дигәнн ышаныч белдерде.

ЛОНДОН. СССР Президенты М. С. Горбачевны дөньяның төп җиде индустриаль иле киңәшмәсендә чакыру турында әле рәсми карар кабул ителмәде, дип белдерде Бөекбритания тышкы эшләр министры Д. Хэрд.

ТОКИО. СССР Президенты Михаил Горбачевны промышленность ягыннан алга киткән җиде ил җитәкчеләре очрашуына чакыру турында Япония соңгы сүзен әйтмәде әле, диде Япония министрлар кабинетының генераль секретаре Мисаодзи Сакамото.

**(ТАСС).**



Өстән кушканны көтеп торырга яратмый ул. Үзлегеннән белеп эшли. Эшкә дә иң беренче булып килә, иң соңыннан кайтып китә. Шуңа да дәрәҗәсе зур авылдашлары алдында Наил Галимҗанович Хәсәнҗановның. 25 ел буена механизатор булып эшләү дәверендә корыч айгырның төрлесен иярләде, штурвал артына да утырды. Тик беркайчан сыкранганын, зарланганын күрмәделәр аның. Әнә хәзер дә көннетөнгә ялгап Т-150 тракторына тагылган агрегат белән язгы чәчүдә катнашты, көнлек норманы 170 процентка кадәр үтәп барды. Техника белән аеруча сак эш итүе өчен дә яраталар аны.

Сабыр холыклы Наил Галимҗанович урып-җыю чорындагы фидакарь хезмәте өчен 1989 елда «Жигули» машинасы белән бүләкләнде, район буенча беренче урынны алды. 1990 елда да сынатмады, «ДОН-1500» комбайны белән 12000 центнер ашлык суктырды. Моңардан тыш кич профильле бу механизаторның башка яклары турында да әйтеп китәргә була. Әйтик, кышкы чорда балта остасы буларак колхоз пилорамында хезмәт куя, бура бурау, такта ярдыру кебек эшләрдә катнаша.

Гаиләсеннән дә уңды ул. Бүгенге көндә Наил Галимҗановичның өч малае да үсеп җитеп үз тормышлары белән көн күрәләр. Өлкән уллары Илшат Норлат шәһәрендәге ремонт-төзелеш участогында эшләсә дә, җәйге чорда әтисенең иске комбайнына утырып, иген уруда булыша. Икенче уллары Раил исә Мәскәү шәһәрендәге югары милиция мәктәбендә криминалистлыкка укый. Бу профессияне сайлавын ул болай дип аңлата: «Армиядә чагында җинаятьчелекнең күзгә күренеп үсүен күреп йөрәгем әрни иде, шуңа да шул юл белән киттем». Кече уллары Радик Тәтештә авыл хуҗалыгы техникумында укый, тиздән армиягә китәргә тора.

Хатыны Саҗидә турында исә аерым юллар кирәк булыр иде. Ул колхозның товарлыклы-сөтчелек фермасында уңган сыер савучылардан санала, хуҗалык буенча икенче урынны алды. Җыеп әйткәндә, Наил Галимҗановичның үзе белән генә түгел, ә гаиләсе белән дә горурланырга була.

Рәсемдә сез «Чишмә» колхозы механизаторы Н.Г. Хәсәнҗановны күрәсез.

# «Сөлчә» дә бер көн

**«Сөлчә»дә адым саен тәнкыйтькә урын табарсыз»,—дигән фикерне күп авыздан ишетергә туры килде. Ни сәбәпле шундый зур хуҗалыкның начар даны таралган соң әле? Чыннан да гел тәнкыйтьләүгә генә лаекмы икән ул?**

**Шул сораулар безне «Сөлчә» совхозына алып килде.**

## Хуҗасызлык нәтиҗәсе

Соңгы елларда совхозның көн күрүе торган саен кыенлаша бара. Эшчеләр белән администрация арасындагы озакка сузылган конфликт совхозның бөтен тармакларына тискәре йогынты ясый. Эшчеләр, җитәкчелек үзе өчен генә яши, совхоз, анда яшәүче халык ихтыяҗын кайгыртмый, диләр. Ә җитәкчелек, үз чиратында, бөтен гаепне эшчеләргә сылтый: совхоз эше өчен тырышучы юк, хуҗалыктан үзләренә генә ташыйлар, дип зарланалар. Үзара килешмәүчәнлек, аңлашылмаучанлык шул хәлгә җитә ки, эшчеләр җитәкче посттагы иптәшләрне вазифаларыннан азат итү турында катгый таләп куюга барып җитәләр. (Бу хакта узган ел ахырында безнең газетада да сүз булган иде). Үткәннәр хакында озынозак сөйләп торуны максат итеп куймыйбыз. Әмма совхозның бүгенге хәле —шундый атмосфераның, шул конфликтның нәтиҗәсе түгелме икән?

—Хуҗалык 19 нчы гасыр белән яшәп ята,—ди совхозның яңа директоры Р. Г. Шәйдуллин. Ул иң элек совхозның техник тәэмин ителешен, мастерскойларның җиһазланышын күздә тотып әйтәдер, бәлки. Хуҗалык хезмәт җитештерүчәнлеге, фермаларның тышкы һәм эчке торышлары ягыннан чыннан да бүгенге көн таләпләре белән яшәүдән ерак әле. Кыр эшләре, язгы, көзге чәчү буенча да иң арттагы урыннарның берсен алып торса, сөт, ит сатуда да арттан ерак китмәгән. Фермалар ташландык хәлгә килгәннәр. Биналарда суык, вакытында тиешле ремонт үткәрелмәгән. Узган ел тирес түгү тракторы булмау сәбәпле, тиресне җиргә генә актарганнар, нәтиҗәдә ферма тирәсенә үтеп керергә юл калмаган.

Үткән ел хуҗалыкта халыкка бозаулар үстерергә тараткан булганнар. Шуңа сылтап, күпме азык бирелгән, ләкин ул да файдасыз. Нигәдер: «бозауларның мөгезләре генә үскән»,—ди яңа директор.

Игенчелектә дә эшләр шәптән түгел. Көзен 1000 гектардан артык җир сөрелмичә калган. Ә быелгы чәчүгә совхоз бер уч орлыксыз килә. Җирне арендага алу турында сүз чыккач, идарәдә йөзләренә канәгатьсезлек билгесе чыга. Бер агайга җир ышанып тапшырган булганнар да, ышанычы акланмаган. Әллә шул хәл үрнәгеннән чыгып, әллә моңа күптән ышанганлыктан, Рафик Габбасович җирне таратырга каршылыгын белдерде. «Бу вакытлы кызыксыну, пропагандага бирелеп кенә колхоз, совхоз җирләрен ялгыз яшәүчеләргә таратырга ярамый. Алар иң күбендә биш ел аңардан файдаланачаклар да, җитәрлек акча җыйгач, ул җирне ташлап качалар»,—ди ул.

Әлбәттә «Сөлчә»дәге бер арендачыга карап кына гомумән аренда турында хөкем итүе авыр, хәзергә сүз совхозда килеп чыккан хәлнең сәбәпләре турында бара.

Иң төп сәбәпне биредә хуҗасызлык дип атыйлар. Совхозның бөтен тармагында хуҗасызлык атмосферасы хөкем сөрә, дөресрәге, хуҗа кулы үтеп кермәгән. Шул сәбәпле эшчеләр дә үз ирекләренә бирелгәннәр, дисциплина какшаган, коллективта оешканлык булмаган. Гомумән, җитәкче белән эшче арасында конфликт, һәрчак киеренке атмосфера булганда, җитештерүчән хезмәт турында сөйләве кыен. Ниһаять, эшчеләр җитәкчелекне алыштыруга ирешәләр...

## Ярдәм юк

Мамык авылы җирендә егермегә якын предприятие, оешмалар эшләп килә. Шуларның иң зурлары—кирпеч заводы, Зүзәй битум заводы, асфальт-битум заводы... Мамыкта булмаган кеше, аның территориясендә шундый предприятиеләр булып, урамнарда асфальт, тирә-якта таш биналардыр дип уйлар бәлки. Һич юк. Шуларның берсеннән дә хуҗалыкка сизелерлек ярдәм юк. Дөрес, эшчеләргә эш сайлау иреге бар, әмма мондый ирек совхозга кыйбатка төшә, эшче куллар җитешми. Мондый ирек дисциплинаны тагын да какшата.

Үз эшчеләренең социаль - көнкүреш шартлары турында предприятиеләр дә кайгыртырга тиеш, әлбәттә. Мисал өчен авыл клубын гына алыйк. Хәер ул клуб дип атаудан да ерак тора, дөресрәге, ташландык бина. Ә янында гына биш ел элек салып куйган яңа клубның фундаменты төрле климат шартларына түзә алмыйча ашалып ята. Клубны салу хуҗалыкара төзелеш оешмасына (начальнигы Н. Б. Мөлеков) йөкләнгән булып чыкты. Алдан совхозның акчасы булмаган, шул сәбәпле төзелеш тукталган. Быел ул төзелеп тапшырылырга тиеш икән. Акча да бүленгән, тик бүгенге көндә дә төзелеш хәрәкәтсез ята. Димәк, аның быел тәмамлануы да шикле.

Әлеге егермеләп предприятие, оешма клуб төзүдә генә булышлык күрсәтә алмыйлар идемени? Ә бит анда эшләүче күпме егет һәм кыз шул клуб тирәсендә каңгырып йөри. Билгеле, клуб бер генә мисал. Ә совхоз белән андагы предприятиеләрнең кулга-кул тотынышып эшләве ике як өчен дә отышлы булыр иде, югыйсә.

## Үзгәрешләр көтелә

Бу совхозга килгәндә аның турындагы караңгы тоннар бераз яктыра төшкән иде. Әлеге конфликттан соң совхозда җитәкчелек алышына. Халык бердәм эшкә тартыла, сүлпәнлек юкка чыга, таләпчән җитәкчегә карата ышаныч туа. Күптән күрелмәгән хәл: иртәнге сәгать 5 тә торып нарядка йөри башлыйлар. Дисциплина, җаваплылык, күтәренке рух игенчелектә дә, терлекчелектә дә сизелә.

Дөрес, совхозның уңышлары турында сөйләргә бик иртә әле. Вакыт күп үтмәде, әмма рухи үзгәреш тә безнең заманда бик кыйммәт бит. Быелгы чәчү кампаниясе эшчеләрдәге бу үзгәрешне раслады. Орлык табудагы кыенлыкларны җиңеп, совхоз соңгарак калып булса да чәчүне тәмамлады. Бер аршин җирнең дә чәчелмичә калмавы өчен көчләрен кызганмадылар эшчеләр. Беренче урында Александр Алексеев—ул барлыгы 1004 гектар мәйданда тукландыру эшләрен башкарды һәм бөртекле культуралар чәчте. Алексей Васильев икенче урынга лаек булды. Язгы кыр эшләре буенча Дмитрий Магарин яхшы күрсәткечләргә ирешә.

Шулай ук терлекчеләр дә күтәренке рух белән эшли башладылар. Сыер савучылардан Рая Сәяхетдинова, бозау караучылар Эмма Шадрова, Нина Мөхәммәтова, терлекче Хасибулла Гамиров һәм башкалар мактауга лаек.

Ферма тирәләре тирестән чистартыла башлады, кырларда су сибү җайланмалары төзәтелә. Бер сүз белән әйткәндә, эшләр җайга салынуга бара. Гомумән, эшкә яңача караш киләчәктә нәтиҗәле эш булачагына өмет тудыра.

**Ф. ГАЛИМОВА.**
**Р. ШӘЙХУЛЛИНА.**

## Ремонт алып барыла

Бу көннәрдә Яңа Иглай мәчетен кирпеч белән тышлау эшләре алып барыла. Моның өчен кирпеч, цемент, ком һәм башкаларны алуда, кайтаруда «Рассвет» совхозы администрациясенең булышлыгы зур. Ул чималны һәм аны кайтару мәшәкатьләрендә дә булышлык күрсәтә.

**Т. ГОБӘЙДУЛЛИН.**

**«Знамя Октября» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасында Юныс Кадыйрович Кавеев турында сүз чыкса, аны тикмәгә генә универсаль кеше дип атамыйлар. Һөнәре буенча ул терлекче дә, механизатор да.**

**Җәйге айлар җитте исә, Юныс Кадыйрович туган колхозына терлек азыгы әзерләүдә һәм урып-җыю эшләрендә булыша, кышын инде яңадан фермага күчә. Юныс Кадыйрович кайсы эштә дә сынатмый: һәрьяклап үзен булдыклы һәм уңган куллы кеше итеп танытты. Агымдагы елның дүрт аенда ул үз карамагындагы профилакторий группасындагы бер яшькә кадәр булган бозаулардан 510 грамм уртача тәүлеклек үсеш алуга ирешә.**

**Аның хезмәттәше Минһәхмәт Гарифуллович Хәйруллин турында да гел җылы сүзләр генә әйтергә була. Яшь бозаулардан яхшы үсеш алу өчен Минһәхмәт Гарифуллович та зур тырышлык куя һәм үз эшендә өлгерлек күрсәтә.**

**Рәсемдә: Ю. Кавеев һәм М. Хәйруллинны алдынгы терлекчеләр слетына килгән вакытта күрәсез.**



# Кесә каракларыннан сакланыгыз

Җинаять статистикасы күрсәткәнчә, соңгы елларда шәхси җинаятьчелек, аерым алганда гражданнарның шәхси милкен урлаулар күбәйде. Алар арасында кесә басуны аерым алырга була. Кесә караклары кешегә зыян итеп кенә калмыйлар, яшьләргә «җиңел кәсеп» табуда йогынты ясыйлар.

Гел бер төрле караклык белән генә шөгыльләнеп, кесә караклары профессионалга әвереләләр. Шуңа да алар белән көрәш катлаулана.

Кесә караклары белән көрәштәге кыенлыкларның иң борчыганы гражданнарның андый төр караклыкның инде күптән бетерелгән булырга тиеш дип уйлауларында. Лекция һәм әңгәмә барышында кайберәүләр «Кесә караклары һаман бармыни?»—дигән сорауны бирәләр. Ә бит районда ел саен берничә кесә басулар факты теркәлә. Болар гадәттә ярминкә һәм сабан туйлары үткәргәндә күп була. Җинаятьчел группировкаларның җинаять эшчәнлеге зонасын үзара бүлешүләре хәзер беркемгә дә сер түгел. Бәйрәм көннәрендә безгә Самара өлкәсе шәһәрләреннән берничә группа кесә караклары килә. Сабан туе һәм ярминкә якынлашу белән уяу булырга чакырабыз.

Һәм иң элек кесә каракларының шәхесләре турында. Әгәр яшь күрсәткечләрен алсак, алар түбәндәгечә характерлана: 18 яшькәчә—5,6 процент, 18 дән 25 кә хәтле—25—28, 25 тән олырак—65 процент. Кесә каракларының күбесе ир-атлар, ә хатын-кызлар нибары 20 процентны тәшкил итә. Кесә басучыларның күбесе II—III группа инвалидлар һәм физик яктан көчсезләр. Шуны да әйтергә кирәк, кесә караклары яшьтән үк физик көчсез булалар, аракы, наркотиклар еш кулланып сәламәтлекләрен югалталар. Профессиональ кесә каракларының тагын бер үзенчәлекләре—тәбәнәк яки урта буйлылык. Тикшерелгән 300 каракның буе 167 сантиметрдан артмаган.

Практика күрсәткәнчә, кесәчеләр үзләренең җинаять һөнәрләренә һәм урлау урыннарына специальләшәләр. Аларны шул билгеләре белән танылар да. Менә аларның кайберләре: «Язучылар». Бу төр караклар кесә яки сумканы пәке яки үткен әйбер белән кисүче. «Ширмач»лар. Плаш, газета, чәчәк бәйләмнәренә яшеренеп урлаучылар. «Шипач»лар. Мондый төр караклар урлау өчен кеше кесәсенә сәнәк сыман итеп ике бармагы белән тыгыла һәм шул чакта башка бармаклары белән кешенең киемен тарта. Урлауның мондый ысулы югары квалификацияле санала. «Селкүче»ләр. Алар очраклы төрткәләшү ярдәмендә кесәдәге акча янчыгын бушаталар. «Балыкчы»лар. Махсус әләктергеч ярдәмендә урлыйлар. «Хирург»лар. Пинцеттан файдаланучылар.

Шуны онытырга ярамый. Кесә каракларының барысы да бик җитез булалар, аларның куллары искиткеч тиз хәрәкәт итә. Моңа аны өлкән иптәшләре өйрәтәләр. Мин бу юлларны газета укучыларны куркыту өчен түгел, ә алар бу проблемага җитди карасыннар һәм сак булсыннар өчен язам.

Ярминкә, сабан туе көннәрендә бигрәк тә сак булырга чакырам. Акчагызны хуҗалык яки кечкенә сумкада сакламагыз. Чөнки караклар 10 секунд эчендә сумкагыздагы акчаны беләләр. Иң кулае акча янчыгын кулда тоту. Курыкмагыз, карак янчыкны кулдан тартып алмый. Бигрәк тә чиратта торганда сак булыгыз. Исегездә тотыгыз, кесә басуларның 90 проценты кешеләрнең җыелып, этешеп-төртешеп чират торган чакларында була. Чиратта торганда чиратсыз керергә омтылучыларга һәм тиз генә китеп баручыларга игътибар итегез. Кесә карагы акчаны кулга төшергәч, тиз генә китүягын карый. Бу көнне алтын әйберләрегезне кимәгез!

Кесәдән әйбер югалу очрагы булса, шунда ук милициягә хәбәр итегез.

**М. ТЯМАЕВ,**
эчке эшләр бүлеге начальнигы урынбасары, милиция майоры.




**Көрнәле Әмзә авылында яшәүче әниебез Суфия Мөбәрәкҗан кызы ӘХМӘТҖАНОВАга 50 яшь тула. Аның сабырлыгы, мөлаемлыгы, киң күңеллеге безнең өчен һәрчак горурлык булды. Кадерле әниебезне юбилее белән котлыйбыз, безне куандырып озак еллар сау-сәламәт, бәхетле яшәвен телибез.**

**Уллары, кызлары, киленнәре, кияве.**

### ТАБЫЛДЫКЛАР ӨСТӘЛЕНӘ

Рәшит Исмәгыйлевич Мифтахов исеменә бирелгән шоферлык таныклыгы табылда.

Югалтучы Маяковская урамы, 2 йортта яшәүче Киямовага мөрәҗәгать итсен.

## БӨЛДЕРҮЛӘР

**Нефть продуктлары белән тәэмин итүче Норлат-Октябрь предприятиесенә даими эшкә электрослесарь, янгын профилактикасы буенча инспектор кирәк. Хезмәткә түләү штат расписаниесе буенча.**

**Адрес: Октябрь урамы, 114 йорт.**

**АДМИНИСТРАЦИЯ.**

x x x

**Норлат тимер юл станциясе АТПсына электромеханик, линия-аппарат залына электромеханик, элемтә буенча элетромеханик кирәк. Айлык хезмәт хакы 300—400 сум, премияләр өстәлә, тимер юлда йөрү бушлай.**

**Белешмәләр өчен Норлат станциясенең өлкән электромеханигы В. И. Григорьевка яки Бөгелмә станциясе ПЧ-10 кадрлар бүлегенә мөрәҗәгать итәргә.**

x x x

**Октябрь хуҗалыкара төзү оешмасы квалификацияле балта осталарын, эретеп ябыштыручыларны, электр һәм газ ярдәмендә эретеп ябыштыручыларны, тәэминат бүлегендә эшли алырдай хезмәткәрләрне даими эшкә чакыра.**

**Хезмәткә түләү эш башыннан-премиаль һәм вакытка карап-премиаль, шуңа 15 процент район коэффициенты өстәлә. Оешманың үзендә сәламәтләндерү комплексы эшли, ярдәмче хуҗалыгы бар.**

**Квалификацияле балта осталарына, электр һәм газ ярдәмендә эретеп ябыштыручыларга ел дәвамында килешү буенча фатирлар биреләчәк.**

**АДМИНИСТРАЦИЯ.**

x x x

**НУЭООСка даими эшкә МТЗ-80дә эшләү өчен тракторчы, ДТ-75тә эшләргә бульдозерчы, ГАЗ-52 һәм КамАЗ (ярымприцеп) машиналарын йөртү өчен шоферлар кирәк.**

**Түбәндәге адрес белән мөрәҗәгать итәргә: Советская урамы, 148 нче йорт. Телефон: 2—26—64.**

x x x

**Октябрь райпосы азык комбинатына даими эшкә баранка цехында эшләү өчен эшчеләр (хатын-кызлар) кирәк. Айлык хезмәт хакы 200—250 сум.**

x x x

**Октябрь МСОсының төзелә торган чистарту корылмаларына ашыгыч төстә каравылчылар кирәк, эш өч сменалы. Хезмәткә түләү 120 сум, өстәмә мәгълүматларны 2—12—44, 2—14—75 телефоны буенча белергә мөмкин.**

**АДМИНИСТРАЦИЯ.**

# ТЕЛЕВИДЕНИЕ

### СИШӘМБЕ 11 ИЮНЬ

### КАЗАН КҮРСӘТӘ

17.05 «Кәгазь патефон». Нәфис фильм.
18.30 Телесеанс. Яшьлек программасы.
19.00 «Татарстан».
19.30 «Диалоглар». КПСС программасы проекты турында.
20.00 «Әлли-бәлли-бәү».
20.10 «Кайсыгызның кулы җылы...» Хәсән Туфанны искә төшерү.
21.35 Тапшырулар программасы.

### I ПРОГРАММА

6.30 «Иртә».
9.05 «Бүдәнә елавы». Нәфис фильм. 2 нче серия.
10.15 Фильм-концерт.
11.00 «Балалар сәгате».
12.00 «ТЯХ».
12.15 «Актуаль репортаж».
12.30 Мультфильм.
13.00 «Халык иҗаты» видеоканалы.
15.00 «ТЯХ».
15.15 «Улым». Нәфис фильм. 2 нче серия.
16.25 «Мавыгучылар дөньясы».
16.40 Док. фильм премьерасы.
17.00 «Чемпионнар белән бергә».
17.35 «Балалар музыка клубы».
18.00 «Интердетектив: беркемгә буйсынмаган криминалистик экспертиза».
18.30 «ТЯХ».
18.45 «Контакт-форум».
19.15 «Нельсон Мандела: ирек алуда җиңел юл юк».
19.50 Россия сайлау алдыннан дәгъвачылар нәрсәләр вәгъдә итә?
21.00 «Вакыт».
21.40 «Бүдәнә елавы». Нәфис фильм. 2 нче серия.
22.55 «Эфирда музыка».
23.25 Док. фильм.
00.30 «ТЯХ».
00.50 «50х50».
02.25 «Бүдәнә елавы». Нәфис фильм. 2 нче серия.

### II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.20 «Эрудитлар өчен күнегү».
9.05 Эстрада концерты.
9.35 Мультфильм.
10.15 «Төньяктан килгән кәләш». Нәфис фильм.
11.30 Док. фильм.
12.30 Кинорежиссер С. Мамилов турында тапшыру.
13.30 Балалар өчен фильм.
14.35 «Солдат мемуарлары». 5 нче фильм.
15.30 Ритмлы гимнастика.
22.40 Док. фильм премьерасы.
23.00 «Хәбәрләр».
23.15 Нәфис фильм.
00.35 «Сеньор Лунджиның тылсымлы бүләге».

### ЧӘРШӘМБЕ 12 ИЮНЬ

### КАЗАН КҮРСӘТӘ

18.00 «Татар җыры-91». Бөтенсоюз конкурсының йомгаклау концерты (1 нче кисәк). 1 бүлек.
19.00 «Татарстан».
19.30 Йомгаклау концертының дәвамы. 2 бүлек. (2 кисәк).
20.35 «Әлли-бәлли-бәү».
20.45 Йомгаклау концертының дәвамы. (3 нче кисәк). 3 бүлек.
21.20 «Нәтиҗә». Лаеш техникумы.
21.50 Реклама.
21.55 Тапшырулар программасы.

### I ПРОГРАММА

6.30 «Иртә».
9.05 «Бүдәнә» елавы». Нәфис фильм. 3 нче серия.
10.15 Док. фильм премьерасы.
10.55 «Җырлаучы Россия». Нәфис фильм. 1 нче серия.
12.00 «ТЯХ».
12.15 «Җырлаучы Россия». Нәфис фильм. 2 нче серия.
13.30 Мультфильм.
13.40 Дөнья халыклары иҗаты.
15.00 «ТЯХ».
15.15 «Теләкләрнең тормышка ашуы».
16.45 «Яклаучы Седов». Нәфис фильм.
17.30 Әхлаклылыкның һәм сәясәтнең яңаруы турында.
18.45 Концерт.
19.50 «Бүдәнә елавы». Нәфис фильм. 3 нче серия.
21.00 «Вакыт».
21.45 Нәфис фильм. «Гел туры килеп тормый».
23.00 «Кинопанорама».
00.30 «ТЯХ».
00.50 «Оперетта, оперетта».
01.50 «Бүдәнә елавы». Нәфис фильм. 3 нче серия.

### II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.20 «Җиңү поэмасы». А. Караманов.
8.55 Док. фильм премьерасы.
9.25 А. Толстой. «Буратино». Фильм-спектакль
10.35 «Адам Смитның акча дөньясы».
11.10 Мультфильм.
11.30 Россиянең дәүләт суверенитетын игълан итүнең бер еллыгы.
11.45 «Тырышучылар».
12.45 «Россия кайтавазы». Халык музыкасы концерты.
13.15 Док. фильм.
13.25 «Хәбәрләр».
13.30 «Трактир тотучы». Фильм-спектакль.
14.45 Бөек Ватан сугышы елларындагы җырлар.
15.20 Док. фильм.
15.45 Балалар өчен фильм.
17.00 «Хәбәрләр».
17.05 «Рәссам һәм гаугалы заман».
22.00 «Россия кыңгыраулары». Шәфкатьлелек кичәсе.
23.00 «Хәбәрләр».
23.15 Шәфкатьлелек кичәсенең дәвамы.
00.00 «Беренче мәхәббәт». Нәфис фильм.

**МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.**

**Учредительләр— халык депутатларының Октябрь район Советы, КПССның партия оешмасы.**

**Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423060, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.**
**ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.**

Газетаны Нурзия **ФӘСХЕТДИНОВА** җыйды. **АСИЯ МОРАТХАНОВА** верстка ясады. Фирдания **ХУҖИӘХМӘТОВА** басты. Корректор—Рәзинә **ШӘЙХУЛЛИНА.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**
**Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.**
**Күләме—1 басма табак. Заказ 72. Тираж 3415.**